**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.07.2023 № 689

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ гомуми белем бирү оешмалары укучыларын туклану белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 16 гыйнварындагы 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 өлешенә, «Мәгариф турында»2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 6.1 өлешенә ярашлы рәвештә, Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, укучыларның баланслы кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 16 гыйнварындагы 21 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районы өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче бүлектә 1.2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырылырга:

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны, өйдә белем алучы инвалид балаларны бушлай ике тапкыр туклану белән тәэмин итәргә, шул исәптән бушлай ике тапкыр туклануны уку көннәре өчен акчалата компенсация белән алмаштырырга мөмкинлек бирергә, бушлай ике тапкыр туклануны ОВЗ белән белем алучыга, инвалид балага гариза нигезендә акчалата компенсация белән алыштыру турында».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Сәйфетдинова З.Р.